

Саранск шәһәрендә егетләр һәм кызлар арасында теннис буенча Ботенроссия ярышлары узды. Аларда илнен 24 шәһәреннән һәм 20 субъектыннан 59 спортчы коч сынашты. Үткән атнада турнирны ябу тантанасы узды. Анда Мордовия башлыгы Артём Здунов һәм Халыкара Олимпия комитеты әгъзасы, Россия Теннис федерациясе президенты Шамиль Тарпищев катнашты.

«Мордовиянен Ботенроссия дә-рәжәсендәге теннис турнирларын уздыру мәйданчыгы булып торуы күнелле. Бу безнен спортчыларны тартып тора, кемнен ин яхшы формада булуын ачыкларга ярдәм итә.

Спорт - ахырга кадәр корәшергә кирәк булган эш! Сезнен алда яна ярышлар күп, һәр спортчыга үз жинүегезне телим», - дип морәжәгать итте Артём Здунов катнашучыларга. Ул шулай ук Шамиль Тарпищев һәм анын Россиядәге хезмәттәшләре оештырган теннис мәктәбе аркасында безнен спортчылар доньяда ин кочлеләр булып кала, дип билгеләп үтте.

Шамиль Тарпищев Артём Здуновка республикада теннис үсешенә керткән олеше очен рәхмәт белдерде: «Мордовиягә, барлык тренерларга һәм ата-аналарга рәхмәт. Теннис артында - киләчәк, бүгенге кондә булган традицияләрне сакларга һәм арттырырга кирәк».

Россия Теннис федерациясе президенты яшь спортчыларга унышлар һәм югары казанышлар теләде: «Бүген безнен ил- теннис доньясында лидер: 2021 ел нәтижәләре буенча Россия теннисчылары момкин булганнын барысын да оттылар!»

Артём Здунов һәм Шамиль Тарпищев турнир жинүчеләренә һәм призерларына бүләкләр тапшырдылар. Кызлар арасында оченче урынны Дарья Садыкова яулады, икенче- Софья Ведерникова, беренче – Милана Сафиуллина. Кирилл Филаретов егетләр арасында бронза призеры булды, Марк Кременский – комеш, Семен Конышев алтын медаль яулады.

Парлы разрядта Артём Ковалев һәм Дмитрий Ряпухин – егетләр арасында оченче, Роман Кожевников һәм Родион Малмыгин - икенче урын нарны яулыйлар, Семен Конышев һәм Леонид Руднев – жинүчеләр иделәр. София Климанова һәм Виктория Седенкова дуэты – кызлар арасында оченче, Софья Ведерникова һәм Милана Сафиуллина дуэты икенче урын яулыйлар, Дарина һәм Дарья Садыковалар парлы разрядта лидер булдылар.